СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

27.12.2024 № 53/5

На №__________от______________

# КАРАР

## Тукай муниципаль районы милкендә булган хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен раслау турында

«Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135–ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы $3^5$ пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары белән расланган Дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яки муниципаль мөлкәткә карата конкурслар яки аукционнар үткәрмичә аренда шартнамәләрен төзү кагыйдәләренең 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Респубоикасы Тукай муниципаль районы милкендә булган хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2024 елның 27.12. 53/5 номерлы карары белән расланган

Тукай муниципаль районы милкендә булган хуҗалык алып бару хокукында яисә оператив идарә хокукында муниципаль мәдәният оешмаларына беркетелгән мөлкәтне арендага тапшыруны килештерү тәртибе

1. Әлеге тәртип Тукай муниципаль районы мәдәният оешмасы (алга таба – муниципаль мәдәният оешмасы) тарафыннан гамәлгә куючы һәм муниципаль мөлкәт милекчесе белән Тукай муниципаль районының хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында муниципаль мәдәният оешмасына беркетелгән муниципаль мөлкәтен (алга таба – мөлкәт) конкурслар яки аукционнар үткәрмичә арендага тапшыруны килештерү процедурасын билгели.

2. Аренда шартнамәсен төзү кирәклеге турында гаризаны карау нәтиҗәләре буенча муниципаль мәдәният оешмасы «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135–ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы $3^5$ пункты, «Дәүләт яисә муниципаль мәдәният оешмаларына хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт яки муниципаль мөлкәткә карата конкурслар яки аукционнар үткәрмичә аренда шартнамәләрен төзү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 9 сентябрендәге 1529 номерлы карары нигезендә мөлкәт милекчесе һәм гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) мөлкәтне гариза бирүчегә арендага бирүне килештерү турында мөрәҗәгать (алга таба – мөрәҗәгать) юллый.

3. Мөрәҗәгатьтә түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

1) күздә тотылган арендачының исеме, аның урнашкан урыны турында белешмәләр, почта адресы һәм контакт телефоны номеры;

2) арендага тапшырырга тәкъдим ителгән хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәт турында белешмәләр;

3) хуҗалык алып бару яисә оператив идарә итү хокукында беркетелгән мөлкәтне арендага бирү аны нәтиҗәлерәк файдалануга ярдәм итәчәген нигезләү;

4) аренда шартнамәсен төзү тәкъдим ителә торган срок;

5) күздә тотылган арендачыны аңа мөлкәтне конкурс яисә аукцион уздырмыйча гына арендага бирү өчен сайлауны хокукый нигезләү:

а) арендачының мөлкәткә ихтыяҗы, мөлкәттән файдаланунының күздә тотылган максатлары;

б) муниципаль мәдәният оешмасына килүчеләргә һәм хезмәткәрләренә җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә сату өчен тәкъдим ителә торган продукция һәм товарлар ассортименты турында мәгълүмат – җәмәгать туклануын оештыру өчен;

в) сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукция ассортименты турында мәгълүмат – ваклап сату белән шөгыльләнүче юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен.

4. Мөрәҗәгатькә түбәндәге документлар теркәлә:

1) мөлкәтне арендалау шартнамәсе проекты;

2) аренда түләвенең базар бәясен бәяләү турында бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән хисап (тапшыру датасына 90 көннән артмаган вакыт белән);

3) күздә тотылган арендачының  (сувенир, нәшрият һәм аудиовизуаль продукцияне ваклап сатуны гамәлгә ашыручы җәмәгать тукалануы оешмасының, юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең) заявка күчермәсе;

4) шәхесне таныклаучы документның күчермәсе һәм Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә (30 көннән артмаган вакыт белән) – шәхси эшмәкәрләр өчен;

5) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә (30 көннән артмаган вакыт белән) – юридик затлар өчен.

5. Муниципаль мәдәният оешмасына мөлкәтнең бер төрен (төрләрен) арендалауга карата ике һәм аннан күбрәк мөрәҗәгать итүчедән гариза кергән очракта, мөрәҗәгать гаризалар кергән көннән чыгып чиратлылык тәртибендә җибәрелә.

6. Башкарма комитет мөрәҗәгатьне һәм аңа теркәп бирелгән барлык документларны алар кергән көннән алып 7 эш көне эчендә карый һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) мөлкәтне арендага тапшыруны килештерергә;

2) мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тартырга.

7. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту өчен нигезләр булып тора:

1) мөлкәтне арендага бирү муниципаль мәдәният оешмасы эшчәнлеген нәтиҗәлерәк оештыруга ярдәм итмәячәк;

2) мөлкәтне арендага бирү максатлары муниципаль мәдәният оешмасының уставында каралган эшчәнлек төрләренә туры килми;

3) мөлкәтне арендага бирү элек чиратлылык тәртибендә кергән гаризага карата мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча килештерелгән.

8. Кабул ителгән карар Башкарма комитет тарафыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты формасында рәсмиләштерелә һәм кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасына җибәрелә.

9. Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында карарда баш тарту сәбәпләрен нигезләү булырга тиеш.

Мөлкәтне арендага бирүне килештерүдән баш тарту турында карар кабул ителгәндә мөрәҗәгать һәм аңа теркәлгән документлар мондый карар кабул ителгән көннән алып 3 көн эчендә муниципаль мәдәният оешмасына кире кайтарыла.

10. Мөлкәтне арендага бирүне килештерү турында кабул ителгән карар мәдәният муниципаль оешмасы тарафыннан мөлкәтне конкурслар яки аукционнар үткәрмичә генә арендалау шартнамәсен төзү өчен нигез булып тора.

11. Муниципаль мәдәният оешмасы аренда шартнамәсе төзелгән көннән алып 10 көн эчендә Башкарма комитетка аренда шартнамәсе төзү турында (арендага бирелгән мөлкәт исемлеген теркәп һәм аны арендага бирү срогын күрсәтеп) язма рәвештә хәбәр итә.

12. Әлеге Тәртип белән җайга салынмаган өлештә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2015 елның 06 апрелендәге 36/12 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрдә һәм муниципаль учреждениеләрдәге күчемсез һәм аеруча кыйммәтле күчемле мөлкәтне сату һәм арендага бирү буенча сделкаларны килештерү тәртибе кулланыла.